ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«БОЛЬШЕФЕДЕРОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ » БУГУЛЬМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЗУР ФЕДЕРЕРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.11.2025г. № 20

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Зур Федоровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»2024 елның 23 сентябрендәге 22 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Зур Федоровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты законнарга туры китерү максатларында

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Зур Федоровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында " 2024 елның 23 сентябрендәге 22 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк булган очракта һәм федераль закон нигезендә мондый шәхси күрсәткечләрне эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булса, Муниципаль хезмәт алуны сорап мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртүгә ризалыгын алуын раслый торган өстәмә документлар тапшыра. Ризалык алуны раслый торган документлар шул исәптән электрон документ рәвешендә дә тапшырылырга мөмкин. Әлеге өлешнең гамәлдә булуы хәбәрсез югалган дип танылган затларга һәм урнашу урыны вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнмәгән эзләнүче затларга кагылмый.;».

1.2. 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктча өстәргә:

«4.1.) Мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләре җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча вәкаләтләрен үтәү өчен ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы ярдәмендә бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә мондый белешмәләр күрсәтелмичә, мондый затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән максатларда мондый затның шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын алу таләп ителми.».

2. Әлеге карар үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Зур Федоровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртиптә басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкчесе** **Ю. Ю. Трофимова**